**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«16» 12 2025 ел № 4195

«2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеге» комплекслы программасын раслау хакында» 2025 елның 2 апрелендәге 1049 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 6 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеге» комплекслы программасын раслау хакында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2025 елның 2 апрелендәге 1049 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карарны интернет челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

**2025-2027 елларга юл хәрәкәте иминлеген арттыру программасы**

| № | Объектларның исеме | Егәрлек | Финанслау чыганаклары | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Җирле бюджет, мең сум | | | |
| | | | 2024 | 2025 | 2026 | |
| 1 | Поселок эчендәге юлларны төзү, ремонтлау һәм реконструкцияләү | км | 2475,00 | 3390,0 | 3330,0 | |
| 2. | Җирлекнең торак пунктларында тукталыш павильоннары урнаштыру | данә | 250,00 | 100,0 | 300,0 | |
| 3. | «Ясалма тигезсезлек» урнаштыру | данә | 655,00 | 705,0 | 705,0 | |
| 4. | Юлларның машиналар йөрү өлешендә разметка | данә | 661,84 | 735,0 | 735,0 | |
| 5. | Авыл җирлегендә юл билгеләре кую | данә | 1015,00 | 620,0 | 480,0 | |
| 6. | Юл яны сервисы объектлары булган участокларда юлларны яктырту | | 70,00 | 0 | 0 | |
| 7. | Металл барьер киртә урнаштыру | | 259,16 | 0 | 0 | |
| 8. | Балалар автомобиль мәйданчыклары, гомуми белем бирү учреждениесе каршында автомобильләр өчен тукталыш мәйданчыгы | | 164, 0 | 0 | 0 | |
| | Барысы: | | 5 550,0 | 5 550,0 | 5 550,0 | |
| | Барлыгы: | | 16 650 ,00 | | | |